**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**

ЧЕРЕМШАНСКИЙ

МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН

**СОВЕТ КУТЕМИНСКОГО**

**СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ**

ул. Клубная, д. 1а, с. Кутема,

Черемшанский район, 423112

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**

ЧИРМЕШӘН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ

**КУТӘМӘ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ**

**СОВЕТЫ**

Клуб урамы, 1- нче «а» йорт, Кутәмә авылы,

Чирмешән районы, 423112

тел./факс +8(84396)

4-30-88

email:Kut.Cmn2@tatar.ru

№ 58 18.05.2022 ел

# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЧИРМЕШӘН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ КҮТӘМӘ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ КАРАРЫ

**Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Күтәмә авыл җирлеге Советының 2014 елның 17 декабрендәге 117 номерлы «Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Күтәмә авыл җирлегендә муниципаль вазыйфаларны биләүгә дәгъва кылучы гражданнарның керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында, шулай ук Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Күтәмә авыл җирлегендә муниципаль вазыйфаларны биләүче затларның керемнәре, чыгымнары, мөлкәтләре һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр бирү турында нигезләмәне раслау хакында»гы карарына үзгәрешләр кертү турында**

2022 елның 1 апрелендә кабул ителгән «Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» гы 90-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Күтәмә авыл җирлеге Советы КАРАР КЫЛДЫ:

1. Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Күтәмә авыл җирлеге Советының 2014 елның 17 декабрендәге 117 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Күтәмә авыл җирлегендә муниципаль вазыйфаларны биләүгә дәгъва кылучы гражданнарның керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында, шулай ук

Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Күтәмә авыл җирлегендә муниципаль вазыйфаларны биләүче затларның керемнәре, чыгымнары, мөлкәтләре һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр бирү турында нигезләмәгә 7 бүлекнең «в» пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәреш кертергә:

«в) хисап чоры өчен (1 гыйнвардан 31 декабрьга кадәр) үз чыгымнары, шулай ук җир кишәрлеге, башка күчемсез милек объекты, транспорт чарасы, кыйммәтле кәгазьләр, (оешмаларның устав (җыелма) капиталларында катнашу өлеше, пайлары) санлы финанс активлары, санлы валюта сатып алу буенча һәр алыш-биреш буенча үз хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының чыгымнары турында, әгәр дә мондый алыш-бирешләрнең гомуми суммасы алыш-бирешкә кадәрге соңгы өч ел өчен әлеге затның һәм аның хатынының (иренең) гомуми кеременнән артып китсә, һәм алыш-биреш кылу өчен чараларны алу чыганаклары турында белешмәләр».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районының Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Кутәмә авыл җирлеге
башлыгы, Совет рәисе Хәйруллин С.Н.